| | |
|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.05.2015 г.Казань № 108/2-пр.

Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү” ведомство программасында катнашу өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу конкурсы турында” 2015 елның 12 мартындагы 37/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының агросәнәгать комплексын инженер-техник тәэмин итү бүлеге башлыгы Р.М. Шәкүров эштән китү сәбәпле,

б о е р ы к  б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү” ведомство программасында катнашу өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу конкурсы турында” 2015 елның 12 мартындагы 37/2-пр номерлы боерыгына (алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә грантлар бирү өчен крестьян (фермер) хуҗалыклары проектларын сайлап алу буенча конкурс комиссиясе каршындагы экспертлар советы составыннан Р.М. Шәкүровны чыгарырга;

экспертлар советы составына Габбасов Илнар Хатиф улын - Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының терлекчелек объектларын механикалаштыру һәм энергия ресурслары секторы мөдирен кертергә.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының икътисад һәм аграр үзгәртеп корулар буенча урынбасары Р.Р. Хәбиповка йөклим.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г.Әхмәтов